КАРАР

26 ноябрь 2019 ел №3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Югары Өскебаш авылы жирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 25.11.2019 һәм 26.22.2019 елда Югарыдаге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районынын Югары Өскебаш авылы, Югары Өскебаш авылы жирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Югары Өскебаш авылының Сабир Ахтямов урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Югары Өскебаш авылындагы юлларны кардан чистарту;
-Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
- Югары Өскебаш авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
-Югары Өскебаш авылындагы чишмәне ремонтлау;
-Югары Өскебаш авылына пожар гидранты сатып алу, урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 173 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 90.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар Югарыдагечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 90 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Өскебаш авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Сорау буенча карарны танырга: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Югары Өскебаш авылы, Югары Өскебаш авылы жирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Югары Өскебаш авылының Сабир Ахтямов урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Югары Өскебаш авылындагы юлларны кардан чистарту;
-Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
- Югары Өскебаш авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
-Югары Өскебаш авылындагы чишмәне ремонтлау;
-Югары Өскебаш авылына пожар гидранты сатып алу, урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар жыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Югарыдәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен жибәрергә.

Авыл жирелеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов